КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1058

Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 321 нче карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2018 ел, 18 сентябрь, 789 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен компенсацияләү өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждение-ләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан

субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 ноябрь, 1063 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин